ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

_________28.10.2025 ______ № 788____

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2025 елның 26 июнендәге 529 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2025 елның 22 сентябрендәге 01-09-21616 хаты нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2025 елның 26 июнендәге 529 номерлы карары белән расланган Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 1.3.1 п. 6 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.2. Регламентның 1 п. түбәндәге эчтәлекле 1.7 пунктча белән тулыландырырга:

«1.7. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы, «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.»;

1.3. Регламентның 2.6.1. п. 5 пунктчаны төшереп калдырырга;

1.4. Регламентның 2.6.2. п. түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча белән тулыландырырга:

«7) mif/mid форматындагы атрибутив мәгълүматсыз Вектор рәвешендәге җир эшләре чикләре (полигоны) яки җир эшләре башкарылган урын турында түбәндәге ысулларның берсе белән белешмәләр:

- МСК 16 системасында җир эшләре урнашкан урын контурының характерлы нокталары координаталары;
- территориясендә җир эшләре башкарыла торган җир кишәрлегенең кадастр номеры;
- картографик яисә топографик нигездә эш башкару урыны чикләре схемасы».

1.5. Регламентның 2.6.3. п. түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) mif/mid форматындагы атрибутив мәгълүматсыз Вектор рәвешендәге җир эшләре чикләре (полигоны) яки җир эшләре башкарылган урын турында түбәндәге ысулларның берсе белән белешмәләр:

- МСК 16 системасында җир эшләре урнашкан урын контурының характерлы нокталары координаталары;
- территориясендә җир эшләре башкарыла торган җир кишәрлегенең кадастр номеры;
- картографик яисә топографик нигездә эш башкару урыны чикләре схемасы».

1.6. Регламентның 2.6.5 п. 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасының башкарма сурәттә чагылдырыла торган гамәлдәге инженерлык челтәрләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына таләпләрне раслау турында» 2025 елның 16 сентябрендәге 1308/о номерлы боерыгында бәян ителгән һәм төшерелгән инженерлык челтәрләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының җир эшләре чикләрендә дөреслеге һәм тулылыгы предметына ресорслар белән тәэмин итүче оешмалар белән килештерелгән 1:500 масштабында җир эшләре чикләрендә векторлы форматта МСК-16 яки WGS 84 (EPSG:3857) координаталар системасында векторлы модель структурасына туры китереп тутырылган семантика белән башкарма сурәт.»;

1.7. Регламентның 2.6.6 п. 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасының башкарма сурәттә чагылдырыла торган гамәлдәге инженерлык челтәрләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына таләпләрне раслау турында» 2025 елның 16 сентябрендәге 1308/о номерлы боерыгында бәян ителгән һәм төшерелгән инженерлык челтәрләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының җир эшләре чикләрендә дөреслеге һәм тулылыгы предметына ресорслар белән тәэмин итүче оешмалар белән килештерелгән 1:500 масштабында җир эшләре чикләрендә векторлы форматта МСК-16 яки WGS 84 (EPSG:3857) координаталар системасында векторлы модель структурасына туры китереп тутырылган семантика белән башкарма сурәт.»;

1.8. Регламентның 2.8.1 п. 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Регламентның 2.6.1 - 2.6.6 пунктлары нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау йә каршылыклы белешмәләре булган яисә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган документларны тапшыру.».

1.9. Регламентның 3.5.2.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Җир эшләрен җитештерүгә ордерны ябу турындагы карар «ТР пространстволы планлаштыру институты» ДБУ белән мәҗбүри килештерелергә тиеш».»;

1.10. 3.3.3.1., 3.4.4., 3.5.2.1.,3.5.2.2. п. һәм 3.5.3. п. «электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә» фразасын «ГИСОГД системасы ярдәмендә» фразасына;

1.11. 3.2.1, 3.4.1, 3.5.1, 3.6.1 п., 3.3.3.1 пп. «Минһаҗев Раил Равил улы» сүзләрен «Парфенов Геннадий Анатольевич» сүзләренә алмаштырырга.

1.12. Регламентка 1 нче кушымтаны, *әлеге документның 1 нче кушымтасы* нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.13. Регламентка 2 нче кушымтаны, *әлеге документның 2 нче кушымтасы* нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.14. Регламентка 3 нче кушымтаны, *әлеге документның 3 нче кушымтасы* нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.15. Регламентка 12 нче кушымтаны, *әлеге документның 4 нче кушымтасы* нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.16. Регламентка 14 нче кушымтаны төшереп калдырырга;

1.17. *Әлеге документның 5 нче кушымтасы* нигезендә 15 нче кушымта өстәргә;

1.18. *Әлеге документның 6 нчы кушымтасы* нигезендә 16 нчы кушымта өстәргә;

1.19. *Әлеге документның 7 нче кушымтасы* нигезендә 17 нче кушымта өстәргә;

1.20. *Әлеге документның 8 нче кушымтасы* нигезендә 18 нче кушымта өстәргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин

1 нче кушымта

**Тышкы төзекләндерү элементлары бозылу белән бәйле**
**җир эшләрен башкаруга**
**ОРДЕР №_________**

«__» _______.20__ел

Заказчы:________________________________________________________________________

Эшләрне башкаручы:
____________________________________________________________________________

Подрядчының адресы һәм телефоны:
____________________________________________________________________________

Субподрядчикның адресы һәм телефоны:
___________________________________________________________________________

Җир эшләре башкару рөхсәт ителә:_________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Эшләрне башкару тәртибе һәм ысулы:
_____________________________________________________________________________

Яшел зонадагы эшләргә таләпләр:

Бозулар белән: ________ кв.м мәйданлы юл өслегең, асфальт өслекне - ____ кв.м, газонны - ______ кв.м.

Җир эшләр башкару **20__елның «___»_____ 20__елның «___»_______кадәр рөхсәт ителә.**

Төзекләндерү башкару һәм тышкы төзекләндерү элементларын бозуга бәйле җир эшләрен җитештерүгә ордерны ябу **20__елның «___»_______кадәр.**

Җитәкче ____________________

Ордерга кушымта
жаваплы зат (прораб, мастер) тарафыннан тутырыла.

Мин,______________________________________________________________________________,
(җаваплы затның Ф.И.А., вазыйфасы, эш урыны)

эшләр башкарыла башларга өч көн кала, эшләр зонасында урнашкан инженерлык коммуникацияләрен эксплуатацияләүче оешма вәкилләрен урынга чакырырга, эшне СНиП һәм җир асты челтәрләрен проектлау һәм салу кагыйдәләре нигезендә башкарырга, югарыда күрсәтелгән барлык шартларны үтәргә һәм эшне ордерда билгеләнгән срокта башкарырга вәгъдә бирәм. Әлеге ордер буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тотарга әзер.

Эшләрне башкарганда төп таләпләр турындагы белешмәлек белән таныштырылдым.

Эшләрне башкаручы__________________________________________________________
(җаваплы затның Ф.И.А., вазыйфасы, эш урыны)

«__» _________ 202__ ел

**Белешмәлек**

1. Эшләр башланганчы җир эшләре башкаруга ордер рәсмиләштерә, эшләрнең башлануы турында объектны карап тотуны һәм техник эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы Оешмага хәбәр итә. Заказ бирүче (төзүче) подрядчыга эшләр башкаруга ордер рәсмиләштерергә вәкаләт бирергә хокуклы.

2. Бозылган юл өслекләрен, яшел утыртмаларны һәм төзекләндерүнең башка элементларын үз акчалары хисабына торгызу өчен җаваплы.

3. Корылмалар һәм деформацияләр килеп чыкканда объектны муниципаль ихтыяҗлар өчен файдалануга кайтару турындагы актка имза салынган көннән алып билгеләнгән срок эчендә торгызу эшләрен башкаруның гарантияле срогын тәэмин итә.

4. Ордерда күрсәтелгән эшләр срогы тәмамланганнан соң өч көн эчендә объектны тышкы төзекләндерү элементларын бозуга бәйле эшләрне башкарганнан соң «АТИ» МКУ вәкиле һәм заказчы вәкиле кул куя торган төзекләндерүне торгызу эшләрен кабул итү акты белән тапшыра.

5. Казу урыны билгеләнгән типтагы койма белән әйләндереп алынырга тиеш, участок «ТР Биектау муниципаль районы Административ – техник инспекциясе» МКУ белән килештерелгән проект белән билгеләнгән чикләрдә урнашырга тиеш.

6. Җир эшләре башкарылган барлык очракларда транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте иминлеге тәэмин ителергә, ишегалларына керү һәм торак биналарга керү юллары буш булырга, траншеялар аша чыгу күперләре урнаштырылырга тиеш.

7. Юл өслеген сүтеп ташлаудан калган материаллар штабельләргә материаллар төрләре буенча салынырга һәм траншеяләрдәге җир белән кушылмаска һәм урам хәрәкәтенә комачауламаска тиеш. Траншеяләрдән чыккан кире салу өчен яраксыз грунтны эш барышында чыгарырга кирәк.

8. Юлларда һәм тротуарларда траншеяләр һәм чокырлар 0,2 м калынлыктагы комлы грунт белән күмелергә, җентекләп тыгызланырга һәм су сибелергә тиеш (җәй көне). Кыш көне траншеяларны һәм чокырларны эрегән комлы грунт белән тыгызлап күмәргә кирәк.

9. Җир асты челтәрләрен салу кагыйдәләрен, ордер һәм кисәтү кәгазе шартларын бозган өчен гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы булалар.

Эшләрне башкаручы ___________________________

2 нче кушымта

**Тышкы төзекләндерү элементлары бозылу белән бәйле**
**авария-торгызу эшләрен башкаруга**
**ОРДЕР №_________**

«__» ________.20__ел

Заказчы: ________________________________________________________________________

(юридик затлар өчен оешманың исеме, ИНН/ физик затлар өчен гариза бирүченең ФИА)

Эшләрне башкаручы:

______________________________________________________________

(оешманың исеме, җаваплы затның ФИА, телефон)

Эшләр төре: __________________________________________________________________

Челтәрләр исеме ______________________________________________________________

Эшләрне башкару адресы:

_____________________________________________________________________________

20___елның «_____» ________________ № ___ ______________________________________
белән килештерелгән _______________________________________________________________
нигезендә,

**20__елның «___»_____ 20__елның «___»_______ кадәр** җир эшләрен башкару рөхсәт ителә, шул исәптән, бозылган төзекләндерү эшләрен тәмамлау.

Эшләр башкару тәртибе һәм ысулы:

______________________________________________________________________

Яшел зонадагы эшләргә таләпләр:

Бозулар белән: ________ кв.м мәйданлы юл өслеген, асфальт өслекне - ____ кв.м, газонны - ______ кв.м.

Җитәче ____________________

Ордер билгеләнгән вакыт эчендә гамәлдә. Эшләрне ордерны тулысынча рәсмиләштергәннән соң гына башкарырга

Ордерга кушымта
жаваплы зат (прораб, мастер) тарафыннан тутырыла.

Мин,_________________________________________________________________________,
(җаваплы затның Ф.И.А., вазыйфасы, эш урыны)

эшләр башкарыла башларга өч көн кала, эшләр зонасында урнашкан инженерлык коммуникацияләрен эксплуатацияләүче оешма вәкилләрен урынга чакырырга, эшне СНиП һәм җир асты челтәрләрен проектлау һәм салу кагыйдәләре нигезендә башкарырга, югарыда күрсәтелгән барлык шартларны үтәргә һәм эшне ордерда билгеләнгән срокта башкарырга вәгъдә бирәм. Әлеге ордер буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тотарга әзер.

Эшләрне башкарганда төп таләпләр турындагы белешмәлек белән таныштырылдым.

Эшләрне башкаручы________________________________________________________
(җаваплы затның Ф.И.А., вазыйфасы, эш урыны)

«__» __________ 202__ ел

**Белешмәлек**

1. Эшләр башланганчы җир эшләре башкаруга ордер рәсмиләштерә, эшләрнең башлануы турында объектны карап тотуны һәм техник эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы Оешмага хәбәр итә. Заказ бирүче (төзүче) подрядчыга эшләр башкаруга ордер рәсмиләштерергә вәкаләт бирергә хокуклы.

2. Бозылган юл өслекләрен, яшел утыртмаларны һәм төзекләндерүнең башка элементларын үз акчалары хисабына торгызу өчен җаваплы.

3. Корылмалар һәм деформацияләр килеп чыкканда объектны муниципаль ихтыяҗлар өчен файдалануга кайтару турындагы актка имза салынган көннән алып билгеләнгән срок эчендә торгызу эшләрен башкаруның гарантияле срогын тәэмин итә.

4. Ордерда күрсәтелгән эшләр срогы тәмамланганнан соң өч көн эчендә объектны тышкы төзекләндерү элементларын бозуга бәйле эшләрне башкарганнан соң «АТИ» МКУ вәкиле һәм заказчы вәкиле кул куя торган төзекләндерүне торгызу эшләрен кабул итү акты белән тапшыра.

5. Казу урыны билгеләнгән типтагы койма белән әйләндереп алынырга тиеш, участок «ТР Биектау муниципаль районы Административ – техник инспекциясе» МКУ белән килештерелгән проект белән билгеләнгән чикләрдә урнашырга тиеш.

6. Җир эшләре башкарылган барлык очракларда транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте иминлеге тәэмин ителергә, ишегалларына керү һәм торак биналарга керү юллары буш булырга, траншеялар аша чыгу күперләре урнаштырылырга тиеш.

7. Юл өслеген сүтеп ташлаудан калган материаллар штабельләргә материаллар төрләре буенча салынырга һәм траншеяләрдәге җир белән кушылмаска һәм урам хәрәкәтенә комачауламаска тиеш. Траншеяләрдән чыккан кире салу өчен яраксыз грунтны эш барышында чыгарырга кирәк.

8. Юлларда һәм тротуарларда траншеяләр һәм чокырлар 0,2 м калынлыктагы комлы грунт белән күмелергә, җентекләп тыгызланырга һәм су сибелергә тиеш (җәй көне). Кыш көне траншеяларны һәм чокырларны эрегән комлы грунт белән тыгызлап күмәргә кирәк.

9. Җир асты челтәрләрен салу кагыйдәләрен, ордер һәм кисәтү кәгазе шартларын бозган өчен гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы булалар.

Эшләрне башкаручы ____________________________

3 нче кушымта

**Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында**
**КАРАР**

_______________________________________________________
(мөрәҗәгать итүче физик затның ф. и. а., юридик затның исеме)

_________________елның ______ ____________, №__ ____

___________________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________ турындагы

гариза белән мөрәҗәгатенә бәйле, тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләргә бәйле рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.

2.

Җитәкче ____________________

4 нче кушымта

**Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында КАРАР**

_______________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче физик затның ф. и. а., юридик затның исеме)

_________________елның ______ ____________, №__ ____

_______________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________ турындагы

гариза белән мөрәҗәгатенә бәйле, тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләргә бәйле рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.

2.

Җитәкче ____________________

5 нче кушымта

**Җир эшләрен башкаруга ордерның гамәлдә булу срогын озайту турында**
**ХӘБӘРНАМӘ № _______**

______________________________________________________
(мөрәҗәгать итүче физик затның ф. и. а., юридик затның исеме)

_________________елның ______ ____________, №__ ____

_______________________________________________________________________________

____________________________________________________________________ турындагы

гариза белән мөрәҗәгатенә бәйле, тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча җир эшләрен башкаруга ____ _______, _____ ел, №___ ордерның гамәлдә булу срогын озайту турында карар кабул ителде:

Җитәкче ___________________

6 нчы кушымта

**Җир эшләрен башкаруга ордерны ябу турында**
**ХӘБӘРНАМӘ № _______**

________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче физик затның ф. и. а., юридик затның исеме)

_________________елның ______ ____________, №__ ____

______________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________ турындагы

гариза белән мөрәҗәгатенә бәйле, тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча җир эшләрен башкаруга ____ _______, _____ ел, №___ ордерны ябу турында карар кабул ителде:

Җитәкче ____________________

7 нче кушымта

**Җир эшләрен башкаруга____.____._______ елның №_______**
**(кышкы чорда)**
**ордерга гамәлдә булу срогын үзгәртү турында белешмәләрне һәм тышкы төзекләндерүне өлешчә торгызу эшләрен башкару турында белешмәләрне кертү хакында**
**ХӘБӘРНАМӘ № _______**

____________________________________________________
(мөрәҗәгать итүче физик затның ф. и. а., юридик затның исеме)
_________________елның ______ ____________, №______ җир эшләрен башкару ордерына тышкы төзекләндерүне өлешчә торгызу эшләренең гамәлдә булу срогын үзгәртү турында белешмәләрне һәм башкару турында белешмәләрне кертү хакында

гариза белән мөрәҗәгатенә бәйле, тапшырылган гаризаны карау нәтиҗәләре буенча җир эшләрен башкаруга ордерның гамәлдә булу срогын ____ елның _______ _______ кадәр үзгәртү турында карар кабул ителде.

Тышкы төзекләндерүне өлешчә торгызу эшләрен башкаруга кагылышлы белешмәләргә үзгәрешләр кертергә, атап әйткәндә:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Җитәкче ____________________

8 нче кушымта

**ҖИР ЭШЛӘРЕН БАШКАРУГА ОРДЕРНЫ ЯБУ ТУРЫНДА**
**муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында**
**КАРАР №**

___________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче физик затның ф. и. а., юридик затның исеме)

__________________елның ______ ____________, №__ ____

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________ турындагы

гариза белән мөрәҗәгатенә бәйле, тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләргә бәйле рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Җитәкче ____________________